**Җәүһәрова Ф.Х.**
**КФУ доценты**
**Гарипова Әнисә**
**КФУ, 1103 төркем студенты**

# "ТАҢ СУЫ" АЛУЫ ИМЛӘВЕ ТЕКСТЫ ҺӘМ КОНТЕКСТЫ

Заман фольклористикасында текст һәм контекст мәсьәләләре проблемасы яңа түгел. XX гасырның 70 нче елларында ук Г.А.Левинтон, Б.Н.Путилов, Ю.М.Лотман һ.б. галимнәр фольклор текстының күп компонентлылыгына игътибар итә. Алга таба аларның фикерләрен С.Н.Неклюдов, Т.Б.Дианова, В.Е.Добровольская һ.б. дәвам итә. [1]

Күп еллар дәвамында фольклор өлкәсендәге тикшеренүләр конкрет текстларны гына өйрәнүгә кайтып кала иде. Билгеле әлеге текстлар үз эчендә җитәрлек информация саклый. Ләкин шул ук вакытта бирелгән текстларны гына өйрәнү кайбер фольклор жанрларын аңлау-аңлату өчен җитеп бетми. Текстлар белән беррәрттән контекстны да карау йола, им-томга кагылышлы җанрлар өчен аеруча мөһим. Бронислав Малиновский фикеренчә, контексттан башка карала торган фольклор тексты яши алмый. Чөнки әлеге текстны башкаручы, йола башкарылу урыны-вакыты һ.б. – текстны тулысынча аңлау өчен иң мөһим компонентлар.[2]

М.Х.Бакиров бигеләвенчә, "ырым, асылда, төрле сүз формулалары һәм төрле хәрәкәтләр, ысуллар кулланып, ниндидер хыялый көчләр ярдәмендә кешенең үзен чолгап алган мохиткә йогынты ясарга тырышуы дигән сүз. Гадиләштереп әйткәндә, ырым ул борынгы кешенең үз максатына ирешү өчен сүз һәм хәрәкәт «кодрәтенә» таянып эш итүе, хуҗалык һәм көнкүреш ихтыяҗларын махсус сүз формулалары һәм йола-хәрәкәтләр ярдәмендә хәл итәргә омтылуы. Димәк, ырым сүз белән хәрәкәттән – башкару йоласыннан тора. Чөнки ырым текстларын әйткәндә, гадәттә, махсус йоласы да

[1] http://mdalekseevsky.narod.ru/vestnik-context.pdf
[2] 5 Malinowski B. The Problem of Meaning in the Primitive Languages // Ogden C.K., Richards I.A. Meaning of Meaning. London: Harcourt, Brace & World, Inc., 1923. P. 451–510. Русский перевод: Малиновский Б. Проблема значения в примитив-ных языках // Эпистемология и философия науки. 2005. Т. V. № 3. С. 199–233

башкарылган. Ырымнар туган вакытта ук йола белән тыгыз бәйләнгән булганнар. Менә шуңа күрә дә кайбер фольклорчылар (мәсәлән, В.И.Чичеров) аларны йола фольклоры составында карыйлар да. Ләкин вакыт үтү белән, ырымнарның йола белән бәйлелеге кимегән. Кайчандыр турыдан-туры йола-хәрәкәт белән бәйле текстлар (арбаулар, әфсен-догалар) мөстәкыйль рәвештә дә башкарыла башлаганнар”[3]

Китап тексты белән аермалы буларак, фольклорда текст контексттан башка яши алмый. Контекстта гына ул тулы мәгънәсендә ачыла, аңлашыла, төгәл информация саклана.[4] Н.И.Толстой “текст” терминына биргән билгеләмәсендә “билгеле бер им-томның башкарылу йоласы – мәдәни текст. Им-том йоласын барлык структур берәмлекләр берлеге итеп карарга мөмкин. Ул үз эчендә төрле кодларга кергән элементларны туплый:

- акциональ код (йола – билгеле бер эш-хәрәкәтләрнең башкарылу тәртибе);

- реаль яки предметлы код (им-том башкарылганда билгеле бер көнкүреш предметлары яки махсус җиһазлар кулланыла);

- вербаль код (им-том йоласы билгеле бер сүзтезмә формулалары, дога, теләк, мөрәҗәгать һ.б. белән эш итә);

- персональ код (йола хәрәкәтләре билгеле бер кеше тарафыннан башкарыла һәм нинди дә булса шәхескә, персонажга юнәлдерелгән булырга мөмкин);

- локатив код (эш-хәрәкәтләр тирә-юньдәге билгеле бер предметларга яки гомумән пространстводага бер тарафка (күк, җир, кыйбла һ.б.) юнәлеп башкарыла);

- темпораль код (йола, билгеле булганча, көннең, елның билгеле бер вакытында, берәр мөһим вакыйга алдыннан яки аннан соң башкарыла);

- музыкаль код (им-том тексты белән бергә яки аннан башка);

---

[3] Бакиров М. Х. Татар фольклоры : Югары уку йортлары өчен д-лек. Казан : Мәгариф, 2008.— 359 б.
[4]Завгарова Ф.Х. Вопросы текста и контекста в современной татарской фольклористике//Татарская фольклористика. Исследования молодых/Сборник статей чтений школы молодого фольклориста. - Казань: Ихлас, 2011. - С. -12-17.

-сәнгати код (ритуал символллары, азык-төлек, кием-салым, мөһим прдеметлар һ.б.).”[5]

Им-том йоласын тулысынча аңлау, аңлату өчен барлык элементларны да игътибарга алу мөһим.

Җәйге кыр фольклор практикасы вакытында Саба районының Сатыш, Урта Саба авылларында *“Таң суы”* алуга кагылышлы ырымнарга тап булдык.

Беренче информант Сатыш авылы абыстае Хафизова Әминә Хафиз кызы күрсәткәнчә, таң суы – таң атканчы, беренче этәч кычкырганчы алына. Нигездә, мөмкинлек булганда, чишмә суы файдаланыла. Ләкин, әгәр мондый мөмкинлек булмаса, теләсә нинди агымсу бу эш өчен кулланыла ала. Информантның үз сүзләре белән әйткәндә, *“таң суыннан халык бик шифа таба. Аны кайткач, бик әйбәтләп өшкерәләр: 41 бисмилла, 41 “Көлхуаллаһ”, 41 бисмилла, 41 “Фәлакъ”, 41 бисмилла, 41 “Нас” сурәләре белән. Менә ул бөтен авыртуларга шифа. Электән үк, борынгыдан ук, Рәсүлебез заманыннан ук бозыклар булган, менә шушыны сулар белән өшкереп, шуннан шифа тапканнар”.*

Әлеге ырымның акциональ коды:

1. Су алу;
2. Аны өшкерү;
3. Авыруга эчертү яки аның таң суы белән юындыру.

Реаль яки предметлы код – *“таң суы”* – үзе.

Вербаль код ролендә Коръән сурәләре, ягъни 41 бисмилла, 41 “Көлхуаллаһ”, 41 “Фәлакъ” , 41 “Нас” сурәләре чыгыш ясый. Персональ код таң суын алып өшкерүче һәм авыруда реальләшә. Таң суын алу, әйтеп үтелгәнчә, таң атканчы башкарыла. Су алыну урынына килгәндә, ул агымсудан алына.

Икенче информант, шул ук авылда яшәүче Харисова Фәһимә апа күрсәтүенчә, таң суын алу йоласын башкарганда тагын берничә мөһим

[5] Толстой Н.И. Вторичная функция обрядового символа// Язык и народная культура. Очерки по славянской мифологии и этнолингвистике. М., 1995. С. 167-184

момент бар: әгәр суны чишмәдән алсаң, суга барганда белгән дога-сурәләрне укып барырга, шул ук вакытта бер кешегә дә эндәшмәскә кирәк. Суны алгач, “Раббана” укып, дога кылырга. Кайткан вакытта дәшми кайту мәҗбүри түгел. Темпораль кодта да үзгәреш бар: таң суы чәршәмбе иртән алына. Предметына килгәндә, суны 41 савыт алырга кирәк: нигездә таң суына банка, чиләк белән барганнар, су алу савыты ролендә кашык, касә, чокыр кулланылган. Су алганда Коръән сурәләре: “Аятел-Көрси”, “Нас” укыла. Локатив код – су алучы  кыйбла тарафына карап (савыт та кыйблага юнәлгән булырга тиеш) алырга тиеш. Вербаль код - өшкергәннән соң түбәндәге ырым тексты әйтелә:

*“Алты ара күз, биш кара күз, дүрт куй күз, минем күзем түгелдер, Гайшә Фатыйма күзедер, тьфү-тьфү”...*

Таң суы төрле авыруларны дәвалау өчен, өшкерү өчен кулланыла. Аны эчәргә һәм аның белән юынырга мөмкин.

Урта Саба авылында туып үскән Кыямова Минтаһирә апа сөйләве буенча, таң суы чишмәдән алына. Бер дә булмаса,  үз кранының булса да аласың. Темпораль код – таң суы беренче азан тавышы ишетелүгә, ягъни иртәнге намазга чакырып әйтелгән азан тавышы ишетелүгә алына. Бу турыда кайбер дини китапларда да язылган, дип искәртә информант.  Әлеге авылда яшәп килгән гадәт буенча,  ырым тексты да үзгә, су алганчы башта су хуҗаларыннан рөхсәт сорала:

*Су анасы Сылубикә,*
*Җир анасы Җирәнбикә,*
*Су алырга рөхсәт бир.*

Шуннан соң гына Коръән сурәләре укый-укый су алына, өшкерелә һәм авыруга эчерелә.

Таң суы алу белән беррәттән, Урта Саба авылында Бараәт суы дигән төшенчә дә яшәп килә. Таң суыннан аермалы буларак, әлеге суны бары чишмәдән генә алырга кирәк һәм су кичен кояш баткан вакытта алынырга тиеш. Халыкта яшәп килгән ышану буенча, әлеге су бер елга кадәр

бозылмый. Аны, таң су алгандагы кебек, су хуҗаларыннан рөхсәт сорап алалар. Кайткач, су өшкерелә. Әлеге суны өшкерүче үзе дә куллана ала, шулай ук башкаларга бирергә мөмкин. Информант һәр ай саен Бараәт кичәсе булуын да искәртә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: им-том, ырымнар жанрында текстларны гомумән контексттан башка карау бернинди информация бирми. Мәсәлән, алда әйтеп үтелгән:

*Су анасы Сылубикә ,*

*Җир анасы Җирәнбикә*

*Су алырга рөхсәт бир* -

текстында әлеге тезмәнең таң суына караганлыгын белдерүче бер генә элемент та юк. Текстның су алганда әйтелгәне генә ачык аңлашыла. Шулай ук авыруларны дәвалау, өшкерү өчен кулланылуына да ишарә итүче сүз, формалар юк. Аны аңлау өчен әлеге текст белән бергә реаль (предметлы) кодны тәшкил итүче Коръән сурәләрен дә игътибарга алырга кирәк.

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**

1.http://mdalekseevsky.narod.ru/vestnik-context.pdf

2.Malinowski B. The Problem of Meaning in the Primitive Languages // Ogden C.K., Richards I.A. Meaning of Meaning. London: Harcourt, Brace & World, Inc., 1923. P. 451–510. Русский перевод: Малиновский Б. Проблема значения в примитив-ных языках // Эпистемология и философия науки. 2005. Т. V. № 3. С. 199–233

3.Бакиров М. Х. Татар фольклоры : Югары уку йортлары өчен д-лек. Казан : Мәгариф, 2008.— 359 б.

4.Завгарова Ф.Х. Вопросы текста и контекста в современной татарской фольклористике//Татарская фольклористика. Исследования молодых/Сборник статей чтений школы молодого фольклориста. - Казань: Ихлас, 2011. - С. -12-17.

5.Толстой Н.И. Вторичная функция обрядового символа// Язык и народная культура. Очерки по славянской мифологии и этнолингвистике. М., 1995. С. 167-184

**Чыганаклар:**

1.2011 ел фольклор практикасы кысаларында тупланган материаллар инф. Хафизова Әминә,1933елда Саба районы Сатыш авылында туган, яши).

2. 2011 ел фольклор практикасы кысаларында тупланган материаллар (инф. Харисова Фәһимә, 1936 елда Саба районы Сатыш авылында туган, яши).

3. 2011 ел фольклор практикасы кысаларында тупланган материаллар (инф. Кыямова Минтаһирә, 1932 елгы, Саба районы Урта Саба авылында туган, Байлар Сабасында яши).